**Ә. Ш. ЮСУПОВА (Казан)**

# XIX ГАСЫР ИКЕТЕДДЕ СҮЗЛЕКЛӘРЕ ҺӘМ ТУКАЙ ТЕЛЕ

В статье с сравнительном аспекте анализируется лексика двуязычных словарей татарского языка XIX века и лексика поэзии Г.Тукая. Выделяются фонетические, лексические и морфологические особенности, показывается преемственность татарско-русских словарей XIX века и творчества Г.Тукая

XIX гасыр — XX гасыр башы — татар әдәби теле тарихында яңаруларга, үзгәрешләргә бик бай, үзенчәлекле, катлаулы чор. Бу чорда татар теленең грамматикалары, сүзлекләре төзелә, китап басу эше киңәя, татар халкының тарихы, мәдәнияте, этнографиясе, фольклоры ныклап өйрәнелә башлый. XIX гасыр — XX гасыр башында дөнья күргән күпсанлы грамматикаларда, укыту әсбапларында, сүзлекләрдә татар әдәби теленең нормалары чагылыш таба.

XIX гасырның икенче яртысы икетелле сүзлекләренең күплеге белән аерылып тора. Бу сүзлекләр ике төрле максатта язылганнар: алар русларга татар телен һәм татарларга рус телен үзлегеннән өйрәнүне күздә тотканнар. Шушы сүзлекләр арасында лексик берәмлекләрнең байлыгы, структурасының камиллеге, кулланылган алымнарның яңалыгы белән А.Троянский, С.Кукляшев, К.Насыйри, Н.Остроумов, Ш.Габделгазиз, М.Юнысов хезмәтләре аеруча игътибарга лаек .

Сүзлекләрдә тормышта иң еш кулланылышта булган 100 меңнән артык лексик берәмлек тупланган. Сүзлекләрдә татар теленең шул чордагы фонетик, лексик, грамматик нормалары теркәлгән. Ә аларның күпләп чыгуы XIX гасыр — XX гасыр башында татар телен өйрәнүгә зур ихтыяҗ булу турында сөйли.

Татар тел белеме өлкәсендә шундый зур үзгәрешләр барган вакытта әдәбият мәйданына Г. Тукай чыга.

Сүзлекләрнең һәм Г. Тукай иҗатының якынча бер вакытка туры килүе чагыштырма планда кайбер күзәтүләр ясарга мөмкинлек бирә. Чагыштырулар өчен югарыда аталган сүзлекләрдә тупланган сүзләр һәм Г. Тукайның шигъри әсәрләре алынды.

XIX гасыр — XX гасыр башында сүз башы позициясендә җ-лаш-тыру һәм й-лаштыру параллель кулланылган. Бу факт әлеге күренешнең ул чорда нормалашып өлгермәгәнлеген раслый. Й-лаштыру иске татар теленең китап теле традициясе итеп каралса да, Г. Тукай шигырьләрендә ул аз очрый, ә сүзлекләрдә, киресенчә, өстенлек итә. Мәсәлән, йемеш : **йетмәк** – достигать [Т., 1835, с.278], **йетен** – лёнъ [Т., 1835, с.278], **йетмеш** – семьдесятъ [Т., 1835, с.278], **йер** – земля [Т., 1835, с.286], **йыр** – песня [Т., 1835, с.286], **йелкән** – парусъ [Т., 1835, с.318], **йерән** – рыжій [Т., 1835, с.287], **йелем** – клей [Т., 1835, с.314], **җәдрә** – пуля [Т., 1833, с.392], **җар –** берегъ [Т., 1833, с.393], **җау** – война [Т., 1833, с.418], **җырткыч** – хищный [Т., 1833, с.394], **җурган** – одеяло [Т., 1833, с.395].

Г. Тукай шигырьләрендә җ-лаштыру күренеше күп очрый. Моны урта диалект үзенчәлеге итеп тә күрсәтергә мөмкин.

**Җегет** белән кызлар йөри шаркылдашып,

Боз өстендә тимераяк белән шуып.(«Суык»)

Тотса баштан сачтараш, шылтыр да шылтыр **җон** ага.(«Саташкан»)

**Җәдрә** тиде тугъры төзәп аткан җиргә;

Авып төште Бөркет **җәдрә** берлән бергә.

Сүзлекләрдә теркәлгән һәм Г. Тукай шигырьләрендә кулланылган кайбер сүзләрдә язма әдәби тел традицияләре саклanган. Мәсәлән, **бугдай** – пшеница [Т., 1833, с.219], **агыз** – рот, уста [Т., 1833, с.52], **чыраг** – лучина [Т., 1833, с.466], **капуг** – ворота [Т., 1835, с.65], **б~м**: **муз** [Т., 1835, с.214] – боз; **д~т: дерсәк** [Т., 1833,с.526] – терсәк, **дез** [Т., 1833,с.529] – тез, **дир** [Т., 1833, с.529] – тир, **дезген** [Т., 1833, с.529] – тезген, **дастымал** [Т., 1833, с.530] – тастымал и др.; **т~д**: **тулкын** [Т., 1835,с. 20.] – дулкын и др.

Бу күренешкә Г. Тукай шигырьләреннән мисаллар китереп үтик:

**Сачләрен** үргәч тарап, сикерде төште суга ул. («Су анасы»)

Кичтән йокың кала да,

**Егълап** үтә көндезең.(«Бишек җырулары»)

Күтәргән кул догага, яд итә ул шунда үз **угълын:**

Ходаем, ди, бәхетле булсайде сөйгән, газиз **угълым!**(«Ана догасы»)

Бу елда да **богдай** бик уңган, кыйблаларга таба егылган.

(«Аксак Йосып көе»)

Ул Дөю **уйганды**: дүрт якка **бакар**,

Көфер сүзләр**, агъзыйдин** утлар **сачар**.

(«Печән базары, яхуд яңа кисекбаш»)

Сүзлекләрдә тупланган сүзләрне килеп чыгышлары ягыннан караганда, аларның, нигездә, төрки-татар сүзләре икәнен күрергә була. Алар кешенең тән төзелешенә, туганлык атамалары, тормыш-көнжүреш, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясына карыйлар.Иҗатының төп байлыгы итеп халыкның җанлы сөйләм телен алган Г. Тукай шигырьләрендә дә төрки-татар сүзләре төп урын алып тора.

Шул чор өчен аеруча характерлы булган гарәп-фарсы алынмалары үзөйрәткечләрдә дә Г.Тукай шигырьләрендә дә еш очрый. Сүзлекләрдә бу сүзләр дин, уку, фән өлкәсенә караган төркемнәрдә шактый күп. Бу алынмаларның кайберләре татар телендә актив кулланылышта йөриләр. Мәсәлән, алла, дин, китап, каләм, дәфтәр, рәсем. Ә кайберләре бик сирәк кулланылалар, алар, вакытлар үтү белән, архаик сүзләр рәтенә күчкәннәр: **китабъ –** книга [Г., 1804, с.242; Ш.,1893,с.10], **кагасъ** − бумага [Кр., 1880, с.16], **сабакъ** − урокъ [О., 1892,с.166], **калямъ** – перо [Ш., 1893, с.11; О., 1892, с.144], **калпа** – учитель [О., 1892, с.144], **катъ** – письмо [О., 1892, с.112], **гылем** – знание, учёность[О., 1892, с.58], **акеят** – рассказъ, анекдотъ [О., 1892,с.9], **мядряся** – школа [Г., 1801, с.19], **мяктапъ** – школа [Г., 1801, с.19], **шакирдъ** – ученикъ [Г., 1801,с.19], **алимъ-** мудрецъ [Г., 1801,с.19], **нукта** – точка [Г., 1801,с.19], **тавать** – чернильница [Г., 1801, с.19], **каяпъ**−слово [Г., 1801, с.19], **дярсъ** − лекция [Н., 1878, с.59], просвещение [Н., 1878,с.160], **джэдвялъ** − таблица [Н., 1878, с.201], **дяфтяръ** – тетрадь [Н., 1878, с.59], **рисаля** – книжка [Н., 1878, с.60], **талибъ** – студентъ [Н., 1878, с. 74], **кагидя** – правила [Н., 1878, с. 84], **алифъ бий** –

азбука [Г., 1801, с.2; Ю.,1900, с.8], **ахтари** – словарь [Ю., 1900, с.11], **стазъ** – профессоръ [Ю., 1900, с.55], **нәхү** – грамматика [Т., 1833, с.216], г**ыйлми сарыф, гыйлми нәхү** – грамматика [Г., 1804. с.104], **лисан** − язык, словесно [Т., 1833, с.201], **зәбан, лисан -** язык [Н., 1892, с.225], **лөгать** −**н**аречие [Тр., 1835, с.202], **әлиф-би, Хөрүф хуҗа** − **а**лфавит [Н., 1892, с.5], **фиһрсәт** − **а**лфавит [Т., 1835, с.55], **рәсем хат – п**равописание [Т., 1833, с.548], **куул** − **с**лово, речь, речение [Т., 1835, с.127], с**әхүн** − **с**лово, речение [Т., 1833, с.563]. Хәзерге көндә бу кайбер сүзләрнең мәгънәләрен сүзлекләрдән карамыйча белеп тә булмый. Без, бу очракта, сүзлекләрдә теркәлгән берәмлекләрнең Г. Тукай шигырьләрендә дә очравын күрдек. Мәсәлән,

Ачылмыш яңы гөлләр, бәһрәләр зар,
Вә махсус сухтәләр чөн **хөҗрәләр** вар.(***)

Әнә чүлмәк: аңар катык тутырган,
Менә хәлфә: башы **мантыйк** тутырган.(«Әнә-менә»)

Сәнең эшгареңә, бәнчә, агач, даш билә **рәкъсандыр,**
Агач **рәкъс** итмәмәк шагыйрь улан инсанә йоксаңдыр.(«Пушкинә»)

Йөземнәр көнгә каршы ялтырыйлар **ләгыль,** якуттай.(«Төлке һәм йөзем җимеше»)

Син закон-статьяларга баш имисең — хөррә син,
Әйләнәсең, тулганасың — түгәрәк син, **кәррә** син.(«Гыйлавә»)

Мисаллар күрсәткәнчә, һәр ике чыганакта да уртак сүзләр бар. Димәк, бу сүзләр шул вакытта телдә актив кулланылышта булган дигән нәтиҗә ясый алабыз.

XIX—XX гасыр башында татар теленә рус теленнән һәм рус теле аша Европа телләреннән кергән сүзләр төрле тематик төркемнәргә карыйлар. Сүзлекләрдә рус алынмалары авыл хуҗалыгы, үлчәү берәмлекләре, ай исемнәрен белдерүче сүзләр арасында бар. Аларның бер өлеше татар теленең фонетик закончалыкларына буйсынганнар. Мисал итеп түбәндәге сүзләрне күрсәтергә була: **сука** [Ю., 1900, с.49; Н, 1878, с.72], **камыть** [Ю., 1900, с. 47; Ш.,1893. с. 20; Н., 1878, с.80], **буряня** [Ю., 1900, с.27], **буразна** [Ю., 1900,

с.27; Т., 1833, с.190 ], **лачынка** [Кр., 1880, с.21; О., 1892, с.145], **саламъ** [Кр., 1880, с.21; Ш., 1893, с. 21; К., 1859, с.61; О., 1892, с.170], **эскерт** [Кр., 1880, с.21; О., 1892, с.175], **авень** [Ш., 1893, с.21], **сажинь** [О., 1892, с.168], **мижа** [О., 1892, с.91], **арышъ** [Т., 1833, с.29], **ужымъ** [О., 1892, с.155], **курмы** [О., 1892, с.127], **жяшнекь** [О., 1892, с.90], **лачынка** [О., 1876, с.100; О., 1892, с.145], **сутъ** [О., 1892, с.180], **жалуанжа** [О., 1892, с.68], **жармавайъ** [О., 1892, с.72], **чинь** [О., 1892, с.127], **законъ** [О., 1892, с. 90]. һ. б. Ләкин шуны да әйтергә кирәк: рус алынмалары сүзлекләрдә чагыштырмача аз бирелә.

Г. Тукай лирикасына килгәндә, рус алынмаларыннан иҗтимагый-сәяси темага караган сүзләрнең күплеге күзгә ташлана. Бу күренешне шагыйрьнең революцион вакыйгалар чорында яшәве, сәяси идеаллары белән аңлатырга була. Мисаллар карап үтик:

Бакча эчендә пар каен, яфрак яра ел саен,

Кочак-кочак **доносларны** яудырамын көн саен.(«Кушмый ишан җырлый»)

Тирәк-тирәк ситса була, матур була чаршауга,

Бөтен Казан абыстае **агент** хәзер Варшәуга.(«Авыл җырлары»)

Кайда китте **цензурлык,**

Коллык, тарлык, ким-хурлык?(«Хөррият хакында»)

XIX гасыр—XX гасыр башында дөнья күргән ике телле сүзлекләрдә шул чорның иң актив берәмлекләре генә тупланган. Ләкин бу сүзләрнең бер өлеше, вакытлар үтү белән, телдән төшеп калган, искергән сүзләр рәтенә күчкән. Мәсәлән, **жалау** – завязка у платья [Т., 1833, с.407], **ялау** – флагъ [Т., 1835, с.314], **яс** – трауръ [Т., 1835, с.295], **берлинъ арбасы** – карета [Ю., 1900, с.33], **сяке** – лавка [скамья] [Ю., 1900, с. 55], **ут кюймяси** – пароходъ [Н., 1878, с.16], **ут арбасы** – паровозъ [Н., 1878, с.120], **жилдырга** – лыжи [О., 1876, с.72], **тюсътющеручи** – фотографъ [Ш., 1893, с.7], **сувыкъ темерчи** – слесарь [Ш., 1893, с.7], **ләшкәр** – войско [Т., 1835, с.201], **ямин** – присяга [Т.,1835, с.326], **ту** – знамя [Т., 1833, с.379], **тянкяханя** – монетный дворъ [Т., 1833, с.377], **биняк** – тысяча [К., 1859, с.26], **туман** – большое скопление

людей [О., 1876, с.125; О., 1892, с.205 **танукъ** – свидетель [Ю., 1900, с.47], **табанча** – пистолетъ [Т., 1833, с.5], **айбалта** − секира [Н., 1892, с.11], **алай** – отряд [К., 1859, с.12]һ. б. Мондый сүзләр Г. Тукай шигырьләрендә дә бар:

Яба **җиләнен,** җилдән качадыр —

Ничә япса да, җил аны ачадыр.(«Шәкерд, яхуд бер тәсадеф»)

Җилән — эченә мамык куймый гына киң итеп теккән элекке милли өс киеме. (ТТАС, 3 т. 773 б.)

Шунда **саргаскяр** үзенчә бер горур,

Берлә гаскәргә карап читтә торыр.(«Кисекбаш»ка гыйлавә»)

Сәргаскәр — борынгы сүз. Гаскәр башлыгы дигән мәгънә белдерә. (ТТАС, 2 т. 711 б.)

Улыб бер сүздә бер дәртле җәмәгать,

Чыгыб мәйданә, күстәрде **сәнагать.**(* * *)

Сәнәгать — промышленность. Бу сүз бик күп еллар онытылып торды. Бары соңгы елларда гына кулланылышка керә, матбугатта очрый башлады.

**Табиблек** фәне юк дип тә яманлыйлар, ди, дошманнар.

(«Безне урынсызга яманлыйлар»)

Г. Тукай шигырьләрендә, хәзерге әдәби тел нормаларыннан чыгып караганда, диалекталь булып саналган инфинитивның **-мага/ -мәгә** формасы күзгә ташлана. Бу форма Казан арты сөйләшләре өчен хас, шуңа күрә, аның Г. Тукай шигырьләрендә очравы гаҗәп түгел.

Хәйлә иткән монда да ул таз явыз,

**Белмэгә** мөмкин, рәсемгә баксагыз!(«Таз»)

Күз карашында синең дөнья күренде мәңге төн,

Киттең эзләп син, аны **яктыртмага** идеал утын.(«Даһига»)

**Булмага** мөмкин идең бит бай кеше,

Сәүдәгәрләрнең күгендә ай кеше.(«Өч хакыйкать»)

Өстәп шуны әйтергә була: гомумән, шигъри әсәрләрдә морфологик диалектизмнар күбрәк кулланылалар һәм моны хәзерге тикшеренүләр дә

раслый.

Ә сүзлекләргә килгәндә, анда урын алган диалекталь сүзләр, нигездә, лексик диалектизмнарга карыйлар. Шуңа күрә бу өлкәдә сүзлекләрнең лексик байлыгы һәм Г. Тукай шигырьләрендәге сүзләр арасында уртаклык бик аз ().

XIX гасыр — XX гасыр башында **-мак/-мәк** формалы исем фигыль актив кулланылышта булган. Сүзлекләрдә дә фигыльләр шул формада теркәлгәннәр. Әлеге формалар Г. Тукай шигырьләрендә дә еш очрый. Мәсәлән:

Иртә берлән **кайнамакта** ул базар,

Анда да монда кызадыр сәүдәләр.(«Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш»)

**Ашыкмакта** һәркем дә артыннан куган төсле.(«Тәүлек»)

Көтү-көтү **менмәктә,**

Күккә җитез кошлар да.(«Тәүлек»)

Шулай итеп, XIX гасыр — XX гасыр башында дөнья күргән сүзлекләр, Г. Тукай әсәрләре милли әдәби телнең фонетик, лексик, грамматик нормаларын барлыкка китерүдә зур роль уйнаганнар. Сүзләр арасындагы уртаклыклар нәкъ менә шул турыда сөйли. Г. Тукай сүзлекләрдә, грамматикаларда, үзөйрәткечләрдә булган традицияләрне тагын да үстерә һәм баета. Шагыйрьнең әдәби телне үстерүдәге эшчәнлеге шуның белән билгеләнә. XIX гасыр буе татар әдәби теленең нормаларын эшләү, камилләштерү бара. Бер яктан, бу эшне татар әдәбиятының күренекле вәкилләре башкарса, икенче яктан, ул сүзлекләрдә, үзөйрәткечләрдә чагыла. Шуңа да бу өлкәдәге эзләнүләр кызыклы булып тора.

## ЧЫГАНАКЛАР:

1. Гиганов И. Слова коренные, нужнейшие к сведению для обучения татарскому языку, собранные в Тобольской главной школе учителем татарского языка, Софийского собора священником Иосифом Гигановым и юртовскими муллами свидетельствованные / И. Гиганов. – СПб., 1801. – 75 с.

2.Гиганов И. Словарь российско-татарский, собранный в Тобольском главном народном училище учителем татарского языка И.Гигановым и муллами юртовскими / И. Гиганов. – СПб.: Имп. АН, 1804. – 627 с.

3.Краткий татарско-русский словарь с прибавлением некоторых славянских слов с татарским переводом. – Казань, 1880. – 55 с.; 1882. – 55 с.; 1886. – 96 с.; 1888. – 96 с.; 1891. – 96 с.

Кукляшев С. Словарь къ татарской хрестоматии / С.Кукляшев. – Казань, 1859. – 106 с.

4.Насыри К. Татарско-русский словарь / К. Насыри. – Казань, 1878. – 120 с.

5.Остроумов Н.П. Первый опыт словаря народно-татарского языка по выговору крещеных татар Казанской губернии / Н. Остроумов. – Казань, 1876. –145 с.

6.Остроумов Н.П. Татарско-русский словарь / Н. Остроумов. – Казань, 1892. – 246 с.

**7.**Троянский А.А. Словарь татарского языка и некоторыхъ употребительныхъ въ немъ реченій арабскихъ и персидскихъ, собранный трудами и тщаніемъ учителя татарского языка въ Казанской семинаріи священника Александра Троянского и напечатанный съ дозволенія комиссіи духовныхъ училищъ, в 2 т. / А.А. Троянский. – Казань, 1833. – Т. 1. – 629 с.; – Казань, 1835. – Т. 2. – 340 с.

8. Габдельгазиз Шигабутдин. Перевод съ татарскаго на русский языкъ или словарь / Ш.Габдельгазиз. – Казань, 1893. − 72с.

9. Юнусов М. Татарско-русский словарь наиболее употребительных слов и выражений / М. Юнусов. – Казань, 1900. – 115 с.